КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 сентябрь г.Казань № 767

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында» 2015 ел, 4 март, 132 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында» 2015 ел, 4 март, 132 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«казна учреждениесенең үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле Татарстан Республикасы Дәүләт гербы төшерелгән түгәрәк мөһере, штамплары һәм бланклары бар».

2. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесенең уставын бу карарга туры китерүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин